**Казан шәһәре Башкарма комитетының**
**2024 елның 28 ноябрендәге 4927 номерлы карары**

**Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның**
**1 октябрендәге 5111 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль**
**унитар предприятиеләре ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр,**
**хезмәтләр сатып алу турында»гы карарына**
**үзгәрешләр кертү хакында**

2024 елның 8 августындагы 318-ФЗ номерлы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе закон актларындагы аерым нигезләмәләрнең гамәлдән чыгуын тану турында»гы федераль закон таләпләренә туры китерү максатыннан **карар бирәм**:

1. Казан шәһәре Башкарма комитетының 2018 елның 1 октябрендәге 5111 номерлы «Казан шәһәренең муниципаль унитар предприятиеләре ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында типлаштырылган нигезләмә турында»гы карары (аңа Казан шәһәре Башкарма комитетының 2019 елның 15 апрелендәге 1312 номерлы, 2019 елның 8 июлендәге 2428 номерлы, 2019 елның 27 декабрендәге 4684 номерлы, 2020 елның 28 октябрендәге 3041 номерлы, 2021 елның 13 апрелендәге 865 номерлы, 2021 елның 25 июнендәге 1555 номерлы, 2021 елның 30 декабрендәге 3540 номерлы, 2022 елның 15 июнендәге 1806 номерлы, 2022 елның 1 ноябрендәге 3753 номерлы, 2023 елның 7 мартындагы 670 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Казан шәһәренең муниципаль унитар предприятиеләре ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында типлаштырылган нигезләмәнең кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. IV бүлекнең исемен түбәндәге редакциядә бирергә: «Конкурентлы һәм конкурентлы булмаган сатып алулар уздыру ысуллары, милли режим бирү»;

1.2. IV бүлектә түбәндәге эчтәлекле 4.7 пункт өстәргә:

«4.7. Сатып алуларны башкарганда, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Сатып алулар турында законның 3.1-4 статьясындагы 2 өлешнең 1 пунктында каралган чараларны кабул итү очракларыннан тыш, чит дәүләтләрдә яисә чит дәүләтләр төркемнәрендә (алга таба – чит дәүләт) эшләп чыгарылган товарга, шул ук тәртиптә чит ил гражданины яки чит ил юридик заты (алга таба – чит ил заты) тарафыннан башкарыла торган эшкә, күрсәтелә торган хезмәткә – Россиядә эшләп чыгарылган товарга, Россия гражданины яки Россия юридик заты (алга таба – Россия заты) тарафыннан башкарыла торган эшкә, күрсәтелә торган хезмәткә бирелгән кебек тигез шартлар тәэмин итә торган милли режим бирелә.

Сатып алулар турында законның 3.1-4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пункты нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан кабул ителгән чаралар белән башкасы каралмаган булса, Россиядә эшләп чыгарыла торган товарга, Россия заты тарафыннан башкарыла торган эшләргә, күрсәтелә торган хезмәтләргә кагылышлы 4.7.1 - 4.2 пунктлардагы нигезләмәләр шулай ук Россиядә эшләп чыгарыла торган товар, Россия заты тарафыннан башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр белән тигез шартлар бирелә торган чит дәүләттә эшләп чыгарыла торган товарга, чит ил заты тарафыннан башкарыла торган эшләргә, күрсәтелә торган хезмәтләргә карата да кулланыла.

4.7.1. Товарны сатып алганда:

1) әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Сатып алулар турындагы законның 3.1-4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктындагы «а» пунктчасында каралган товар сатып алуны тыю билгеләнгән булса, түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

а) мондый товарны китерүгә килешү төзү;

б) килешүне үтәгәндә, мондый товарны чит дәүләттән булган, аңа карата әлеге тыю билгеләнгән товарга алмаштыру;

2) әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Сатып алулар турындагы законның 3.1-4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктындагы «б» пунктчасында каралган товар сатып алуны чикләү билгеләнгән булса, түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

а) сатып алуда катнашуга гариза бирелгән булса, аларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең, конкурентлы сатып алу турында хәбәрләмәнең (конкурентлы сатып алу үткәрелгән очракта), конкурентлы сатып алу турындагы документларның (конкурентлы сатып алу үткәрелгән очракта) таләпләренә туры килә торган дип танылган һәм Россиядә чыккан товарны китерү турында тәкъдимнәр булган – чит дәүләттә чыгарылган товарны

китерүгә килешү төзү, соңгы тәкъдим;

б) әгәр күрсәтелгән килешү Россиядә чыккан товарны китерүне күздә тота икән, килешүне үтәгәндә, товарны үзенә карата әлеге чикләү билгеләнгән, чит дәүләттән булган товарга алмаштыру;

3) әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Сатып алулар турында законның 3.1-4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктындагы «в» пунктчасында каралган Россиядә чыккан товарга карата өстенлекләр билгеләнгән икән:

а) сатып алуда катнашуга гаризаларны, соңгы тәкъдимнәрне карап тикшергәндә, бәяләгәндә, чагыштырганда, китерүгә бары тик Россиядә чыккан товарны гына тәкъдим итә торган сатып алуда катнашучы тарафыннан сатып алулар турындагы Закон һәм әлеге Нигезләмә нигезендә бирелгән бәя тәкъдиме унбиш процентка киметелә яки килешү төзегән өчен кертелергә тиешле түләү күләме турында әлеге сатып алуда катнашучы тарафыннан тәкъдимнәр бирелгән очракта, аның тарафыннан бирелгән бәя тәкъдиме унбиш процентка арттырыла;

б) әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән сатып алуда катнашучы белән килешү төзелгән очракта, килешү әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырылган бәя тәкъдимнәрен киметүне яисә арттыруны исәпкә алмыйча төзелә;

в) килешүне үтәгәндә, әгәр күрсәтелгән килешү Россиядә чыккан товарны китерүне күздә тота икән, товарны бары тик Россиядә чыккан товарга алмаштыру рөхсәт ителә.

4.7.2. Эш, хезмәтләр сатып алганда:

1) әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Сатып алулар турындагы законның 3.1-4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктының «а» пунктчасында каралган чит ил заты тарафыннан башкарыла торган эшне, күрсәтелә торган хезмәтне тыю билгеләнгән булса, түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

а) мондый эшне башкару, хезмәтне күрсәтү өчен чит ил заты булып торучы подрядчы (башкаручы) белән килешү төзү;

б) әлеге килешү төзегән подрядчыны (башкаручыны) чит ил территориясендә теркәлгән, аңа карата әлеге тыю билгеләнгән чит ил затына алмаштыру (әгәр бу алмаштыру гражданлык законнарында рөхсәт ителгән булса);

2) әгәр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Сатып алулар турындагы законның 3.1-4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктының «б» пунктчасында каралган чит ил заты тарафыннан башкарыла торган мондый

эшне, күрсәтелә торган хезмәтне чикләү билгеләнгән булса, түбәндәгеләр рөхсәт ителми:

а) сатып алуда катнашуга Россия заты тарафыннан гариза бирелгән булса, сатып алуда катнашучы белән килешү төзү, карап тикшерү нәтиҗәләре буенча әлеге Нигезләмәнең, конкурентлы сатып алуны башкару турында хәбәрләмәнең (конкурентлы сатып алу үткәрелгән очракта), конкурентлы сатып алуны башкару турындагы документларның (конкурентлы сатып алу үткәрелгән очракта) тиешле таләпләренә туры килә дип танылган соңгы тәкъдим;

б) килешү төзегән подрядчыны (башкаручыны) чит ил дәүләте территориясендә теркәлгән, аңа карата әлеге чикләүләр билгеләнгән чит ил затына алмаштыру (әгәр дә бу үзгәртү гражданлык законнарында рөхсәт ителгән булса), әгәр мондый килешү Россия заты белән төзелгән булса;

3) Россия заты тарафыннан башкарыла торган мондый эшләргә, хезмәтләргә карата Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан Сатып алулар турында законның 3.1-4 статьясындагы 2 өлешенең 1 пунктындагы «в» пунктчасында каралган өстенлек билгеләнгән булса:

а) конкурентлы сатып алуда катнашуга гаризаларны, конкурентлы булмаган сатып алуда катнашуга гаризаларны, соңгы тәкъдимнәрне карап тикшергәндә, бәяләгәндә, чагыштырганда Сатып алулар турындагы закон һәм әлеге Нигезләмә нигезендә бирелгән бәя тәкъдимен Россия заты булып торучы сатып алуда катнашучы тарафыннан унбиш процентка киметү яки әлеге сатып алуда катнашучы белән килешү төзү өчен кертелергә тиешле түләү күләме турында аңардан тәкъдим кергән очракта, аның бәя тәкъдимен унбиш процентка арттыру башкарыла;

б) әлеге пунктның «а» пунктчасында күрсәтелгән сатып алуда катнашучы белән күрсәтелгән килешү төзелгән очракта, килешү әлеге пунктның «а» пунктчасы нигезендә гамәлгә ашырылган бәя тәкъдимнәрен киметүне яки арттыруны исәпкә алмыйча төзелә;

в) күрсәтелгән килешү Россия заты белән төзелгән булса, килешү төзегән подрядчыны (башкаручыны) бары тик Россия затына гына алмаштыру рөхсәт ителә (әгәр дә бу үзгәртү гражданлык законнарында рөхсәт ителгән булса).

4.7.3. Ел йомгаклары буенча хисап елыннан соң килүче елның 1 февраленә кадәр бердәм мәгълүмат системасында сатып алулар нәтиҗәләре буенча Заказ бирүче тарафыннан төзелгән килешүләр реестрына кертелгән һәм бердәм мәгълүмат системасында булган мәгълүматны эшкәртү юлы белән, шулай ук Заказ бирүче тарафыннан, Сатып алулар турында закон нигезендә алар турындагы мәгълүмат бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга

тиеш булмаган сатып алулар күләме турындагы мәгълүматны формалаштыру юлы белән формалаштырыла торган, Россия затлары тарафыннан башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләрләр, Россиядә чыгарылган товарларны сатып алу күләме турында хисап бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла.

Россиядә чыккан товарларны, Россия затлары тарафыннан башкарыла торган эшләрне, күрсәтелә торган хезмәтләрне сатып алулар күләме турындагы хисап бердәм мәгълүмат системасында урнаштырылырга тиеш булмаган очракларда Заказ бирүче хисап елыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр мондый хисапны төзи һәм федераль башкарма хакимият органына җибәрә».

2. «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесенә (Р.Г.Галәветдинов):

2.1. 2.1. әлеге карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә әлеге карарны Казан шәһәренең муниципаль унитар предприятиеләре җитәкчеләре игътибарына җиткерергә;

2.2. Казан шәһәренең муниципаль унитар предприятиеләре ихтыяҗлары өчен товарлар, эшләр, хезмәтләр сатып алу турында типлаштырылган нигезләмәгә кертелгән үзгәрешләрне сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында (www.zakupki.gov.ru) 2024 елның 28 ноябреннән дә соңга калмыйча урнаштырырга.

3. Әлеге карарны «Муниципаль хокукый актлар һәм башка рәсми мәгълүмат» челтәр басмасында (www.docskzn.ru) бастырып чыгарырга, Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының рәсми порталында (www.kzn.ru) һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **Р.Г.Гафаров**